# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр
кертү хакында**

**1 статья.** «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1997 елның 2 июлендәге 1243 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 7) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларын дәүләт тарафыннан исәпкә алу

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы индивидуаль эшкуарлар һәм юридик затлар барлыкка килгән, кулланылган, зарарсызландырылган, башка затларга тапшырылган яисә башка затлардан алынган, шулай ук урнаштырылган калдыкларны билгеләнгән тәртиптә исәпкә алырга тиеш.

Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибе законнар белән билгеләнә.».

2. 7 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү һәм урнаштыру лимитлары индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга законнарда билгеләнгән тәртиптә билгеләнә.».

3. 8 статьяда:

беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләү индивидуаль эшкуарлардан һәм юридик затлардан Россия Федерациясе законнары нигезендә алына.»;

икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыкларны урнаштырган өчен түләүнең дифференциацияләнгән ставкалары, башкарма хакимиятнең калдыклар белән эш итү өлкәсендәге махсус вәкаләтле федераль органнары белән килешеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан законнар нигезендә билгеләнә.».

4. 9 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә икътисадый кызыксындыру

Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә икътисадый кызыксындыру законнар нигезендә түбәндәге юллар белән башкарыла:

– процессы дәвамында калдыклар барлыкка килерлек эшчәнлек белән шөгыльләнүче индивидуаль эшкуарларга һәм юридик затларга калдыкларның микъдарын киметүне тәэмин итәрлек технологияләрне гамәлгә керткәндә калдыкларны урнаштырган өчен түләү күләмен киметү;

– калдыклар белән эш итү өлкәсендәге эшчәнлекне башкаруга бәйле төп җитештерү фондларының тизләтелгән амортизациясен куллану.».

5. 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. Куркыныч калдыклар белән эш итү эшчәнлеген лицензияләү

Куркыныч калдыклар белән эш итү эшчәнлеге федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә лицензияләнергә тиеш.».

6. 11 статьяда:

беренче өлешендә «әлеге Закон» сүзләрен «законнар» сүзенә алмаштырырга;

икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыкларга идарә итү предприятиеләрен, корылмаларын һәм башка объектларын төзү урыннарын билгеләү табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарының, санитар-эпидемиология күзәтчелегенең уңай бәяләмәсе һәм дәүләт идарәсенең җирле органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары булганда башкарыла.»;

дүртенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эксплуатацияләнүләре калдыклар белән эш итүгә бәйле предприятиеләрне, биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне һәм башка объектларны төзү, реконструкцияләү, консервацияләү һәм бетерү уңай дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе булганда гына рөхсәт ителә. Фәнни коллективлар, иҗтимагый берләшмәләр инициативасы буенча үткәрелүче иҗтимагый экология экспертизасы нәтиҗәләре дәүләт экология

экспертизасының тиешле органнары тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.»;

җиденче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыкларны шәһәр һәм башка торак пунктлары, урман-парк, курорт, дәвалау-савыктыру, рекреация зоналары, шулай ук су саклау зоналары территорияләрендә, эчәр сулар һәм хуҗалык-көнкүреш сулары белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты су объектларының су җыю мәйданнарында күмү тыела. Файдалы казылмалар яткан җирләрне пычрату куркынычы һәм тау эшләрен алып бару хәвефлелеге килеп чыгу очракларында, калдыкларны файдалы казылмалар яткан һәм тау эшләре алып барыла торган урыннарда күмү тыела.»;

тугызынчы өлешендә «әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге» сүзләрен «табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау» сүзләренә алмаштырырга.».

7. 13 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Калдыкларга идарә итүне гамәлгә ашыручы предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау һәм санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендә махсус вәкаләтле дәүләт органнарына, шулай ук тау эшләре һәм сәнәга күзәтчелеге органнарына, шушы органнарның таләбе буенча, җитештерелгән һәм саклanучы калдыкларның микъдаре, характеры һәм аларны күчереп йөртү турында тулы дөрес мәгълүмат бирергә тиешләр.».

8. 15 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә дәүләт экология контроле

Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә дәүләт экология контроле башкарма хакимиятнең калдыклар белән эш итү өлкәсендәге махсус вәкаләтле федераль органнары тарафыннан үз компетенциясе нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, дәүләт хакимияте һәм идарәсенең җирле органнары, шулай ук табигый байлыклардан файдалану, аларны торгызу, саклау һәм әйләнә-тирә мохитне саклау, санитария-эпидемиология күзәтчелеге өлкәсендәге махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан законнар нигезендә башкарыла.».

9. 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«16 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә җитештерү экология контроле

Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендәге эшчәнлекне гамәлгә ашыручы предприятиеләрнең, учреждениеләрнең,

оешмаларның экологик хезмәтләре калдыкларга идарә итү өлкәсендәге законнар таләпләренең үтәлешен житештерү ягыннан тикшереп торуны оештыралар һәм башкаралар.».

10. 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә иҗтимагый экология контроле

Җитештерү һәм куллану калдыкларына идарә итү өлкәсендә иҗтимагый экология контроле иҗтимагый берләшмәләр, гражданнар тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

11. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«21 статья. Җитештерү һәм куллану калдыкларын чиктәш күчереп йөртү

Җитештерү һәм куллану калдыкларын чиктәш күчереп йөртү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.».

12. 22 статьяны төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 25 октябре
№ 1144